ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $1^1$ статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артык булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы урыннарга карата салым базасы аларның билгеләнгән тәртиптә расланган кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә.»;

2) 2 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Салым базасы кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә торган күчемсез мөлкәт объектларына карата салым ставкасы 2 процент күләмендә билгеләнә.»;

3) 3 статьяда:
а) түбәндәге эчтәлекле $3^2$ өлеш өстәргә:

«$3^2$. Салым әлеге Законның $1^1$ статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән күчемсез милек объектларына карата исәпләнгән салым суммасының 60 проценты күләмендә түләнә, халык саны 145 мең кешедән артык булган торак пунктлар территорияләрендә урнашкан гомуми мәйданы 2000 квадрат метрдан артык сәүдә үзәкләре (комплекслары) һәм алардагы урыннар моңа керми.»;

б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Салым түләүчеләргә әлеге статьяның 1 – $3^1$ өлешләрендә билгеләнгән салым ташламалары салым базасы кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә торган күчемсез мөлкәт объектларына карата бирелми.»;

4) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

«13) 2028 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясының $3^2$ өлешен.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 26 июль
№ 66-ТРЗ